3.5.3. 3.5.3. Идарә башлыгы хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектын (баш тарту турында карар проектын), бергә юллана торган хатны карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктлары билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм Бүлек белгеченә юлланган хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проекты (баш тарту турында карар проекты), бергә юллана торган хат.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектын (баш тарту турында карар проектын), бергә юллана торган хатны хокукый экспертиза өчен хокук идарәсенә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан көндә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелеп, Хокук идарәсенә юлланган хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проекты (баш тарту турында карар проектын), бергә юллана торган хат.

3.5.5. Хокук идарәсе белгече хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектына (баш тарту турында карар проектына) хокукый экспертиза ясый, хокук идарәсе башлыгына хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектын (баш тарту турында карар проектын), бергә юллана торган хатны – килештерү өчен яисә, хокук идарәсе бәяләмәсе проектын (кисәтүләр булган очракта) имзалау өчен юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектына (баш тарту турында карар проектына) кисәтүләр булган очракта, хокук идарәсе бәяләмәсе проекты, яисә хокук гамәлдән чыгарылу турында килештерелгән һәм хокук идарәсе башлыгына юлланган карар проекты (баш тарту турында карар проекты), бергә юллана торган хат.

3.5.6. Хокук идарәсе башлыгы хокук гамәлдән чыгарылу турында карар проектын (баш тарту турында карар проектын), бергә юллана торган хатны килештерә яисә хокук идарәсе бәяләмәсенә кул куя һәм Бүлек белгеченә юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

